Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Явлаштау торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

07.11.2019 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 21 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең Явлаштау торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Явлаштау авыл җирлеге Явлаштау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Явлаштау авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/evlashtay бастырып чыгарырга.

Явлаштау авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев